**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3055**
**17.04.2023**

Яр Чаллы шәһәренең «Мәдәният һәм ял паркы» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктчасы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Мәдәният һәм ял паркы» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитет карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Яр Чаллы шәһәренең «Мәдәният һәм ял паркы» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2022 елның 20 апрелендәге 2079 номерлы;

2) «Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Мәдәният һәм ял паркы» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2022 елның 20 апрелендәге 2079 номерлы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 3 октябрендәге 5190 номерлы;

3) «Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Мәдәният һәм ял паркы» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2022 елның 20 апрелендәге 2079 номерлы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 1 ноябрендәге 6015 номерлы.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 17 апрелендәге
3055 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «Мәдәният һәм ял паркы» МУП
тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге (бер сеанс) | Чик тариф сумнарда |
|---|---|---|---|
| Балалар аттракционнары | | | |
| 1 | Карнавал | 3 мин | 50 |
| 2 | Кыңгырау | 3 мин | 50 |
| 3 | Юнга | 3 мин | 50 |
| 4 | Рельстагы джип | 3 мин | 50 |
| 5 | «Мультфильм геройлары» мультпоезды | 3 мин | 70 |
| 6 | «Миниаэропорт» каруселе | 3 мин | 60 |
| 7 | Кояшкай | 3 мин | 50 |
| 8 | «Җилкәй» балалар чылбыры | 3 мин | 70 |
| 9 | Җиләк-җимешләр | 3 мин | 110 |
| 10 | Батут | 10 мин | 110 |
| 11 | Күңелле утыргыч | 3 мин | 110 |
| 12 | Индеецлар елгасы | 5 мин | 70 |
| 13 | Мини-джет | 3 мин | 70 |
| 14 | «Аквазорб» су шары | 3 мин | 150 |
| 15 | Диңгездә ау | 3 мин | 150 |
| 16 | Балалар өчен чылбырлы карусель | 3 мин | 100 |
| 17 | Көнгерә | 3 мин | 110 |
| Гаилә аттракционнары | | | |
| 18 | Көлке бүлмәсе | - | 20 |
| 19 | Тир | 5 выстрелов | 50 |
| 20 | Экспресс-Шоссе | 10 мин | 90 |
| 21 | Орбита | 3 мин | 110 |
| 22 | Күңелле таулар | 3 мин | 130 |
| 23 | «Сафари» тиры | 3 мин | 70 |
| 24 | Автодром (1 машина) | 3 мин | 160 |
| 25 | Судагы көймәләр (1 көймә) | 3 мин | 150 |
| 26 | Күзәтү тәгәрмәче | 7 мин | 170 |
| 27 | Гусеница | 3 мин | 90 |
| 28 | Аккошлар (1 кабина) | 3 мин | 150 |
| 29 | Туй каруселе | 3 мин | 100 |
| 30 | ФутуРифт виртуаль чынбарлык | - | 150 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Экстремаль аттракционнар | | | |
| 31 | Өермә | 3 мин | 100 |
| 32 | Сюрприз | 3 мин | 70 |
| 33 | Вальс | 3 мин | 160 |
| 34 | Астронавт | 3 мин | 160 |
| 35 | Оча торган тәлинкә | 3 мин | 160 |
| 36 | Жемчужина | 3 мин | 160 |
| 37 | Зодиак | 3 мин | 160 |
| 38 | Оча торган голландияле | 3 мин | 160 |
| 39 | Стелла-Магнетик | 3 мин | 160 |
| 40 | Хип-Хоп | 3 мин | 160 |
| 41 | Биоробот | 3 мин | 160 |
| 42 | Чылбырлы карусель | 9 мин | 160 |
| 43 | Зигзаг | 4 мин | 160 |
| Спорт һәм ял өчен прокатка инвентарь бирү буенча хезмәтләр | | | |
| 44 | Тимераяклар | 1 сәгать | 120 |
| 45 | Тимераяклар (14 яшькә кадәрге балалар) | 1 сәгать | 90 |
| Сервис хезмәтләре | | | |
| 46 | Бәдрәф | 1 тапкыр керү | 10 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева